**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кремлевская ул., д. 9; Казань, 420111
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**

Кремль урамы, 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111,
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының мәгариф идарәләре һәм бүлекләре җитәкчеләренә

III республикакүләм Габдулла Тукай укулары үткәрелү турында

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы Габдулла Тукайның тууына 128 ел тулу, 2014 нче ел Россия Федерациясендә Мәдәният елы дип игълан ителү уңаеннан, яшь буынга рухи-әхлакый тәрбия бирүдә татар халкының бөек шагыйре Г. Тукайның әсәрләрен пропагандалау һәм укучыларда фәнни-тикшеренү күнекмәләре, иҗадилык формалаштыру максатыннан, **2014 нче елның 24 нче апрелендә** III республикакүләм Габдулла Тукай укулары үткәрелүен хәбәр итә.

Үткәрү урыны: Арча муниципаль районы Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе базасы.

Белешмәләр өчен телефоннар: 8(843) 663-30-12 (Арча муниципаль районы мәгариф идарәсе); 8(843) 665-67-36 (Арча районы Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе).

Нигезләмә теркәлә (кушымта): 3 биттә 1 экземплярда.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасының
мәгариф һәм фән министры Э.Н. Фәттахов

А.С. Шәрипова, 294-95-09

**III республика Габдулла Тукай укулары нигезләмәсе**

Габдулла Тукай укулары шагыйрьнең тууына 128 ел тулу уңаеннан иҗади мирасын өйрәнү, 2014 нче ел Россия Федерациясендә Мәдәният елы дип игълан ителү, яшь буынга рухи-әхлакый тәрбия бирүдә әдипнең әсәрләрен пропагандалау максатыннан үткәрелә.

**Максаты һәм бурычлары:**

- Габдулла Тукайның иҗади мирасын һәм аңа бәйләп хәзерге заман әдипләренең иҗатын тирәнтен өйрәнү, пропагандалау;
- укучыларда фәнни-тикшеренү күнекмәләре формалаштыру;
- халкыбызның тарихы, мәдәнияте, милли үзенчәлекләре белән кызыксындыру тәрбияләү;
- фәнни эзләнүләрдә иҗадилыкка омтылышларын булдыру;
- сәләтле балаларны ачыклау һәм аларны үстерү өчен шартлар тудыру;
- укучыларда әдәби иҗатка омтылыш тәрбияләү.

**Катнашучылар:**
Гомуми белем оешмаларының 8-11 нче сыйныф укучылары.

**Габдулла Тукай укуларын үткәрү шартлары һәм тәртибе:**

Габдулла Тукай укулары 2014 нче елның 24 нче апрелендә Арча муниципаль районы Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбендә үткәрелә.

Укучы үзе сайлаган темага иҗади эш (эзләнү эше, реферат, доклад, конкрет методика белән эшкәртелгән практик яки эксперименталь материал булырга мөмкин) әзерли.

**Эшләр түбәндәге юнәлешләрдә тәкъдим ителә:**

1. Габдулла Тукай иҗатында балачак темасы хатирәләренең сәнгатьчә сурәтләнүе һәм тәрбияви әһәмияте.
2. Габдулла Тукай иҗатында татар халкының гореф-гадәтләре чагылышы.
3. Бүгенге сәнгатьтә Тукай образы.
4. Әдәби әсәрләрдә авылым тарихы (эзләнү эшенең җирле материалларга нигезләнгән булуы шарт).
5. «Кышкы кичнең озынлыгын сизмисез дә Әнкәгезнең сөйләгәне әкият берлә” (Г.Тукай). Укучыларның мәктәп, балачак темасына үзләре иҗат иткән маҗаралы әкият жанрындагы әсәрләре (проза-әкият, шигъри әкият).

**Материаллар татар телендә кабул ителә.**
Текстның күләме 8 басма биттән артмаска тиеш.

Эзләнү эшендә күрсәтмә материаллар (рәсем, схема һәм карта, таблица, фоторәсемнәр булырга мөмкин).

**Эшләрнең язылу тәртибе:**

Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman-14, интервал 1,5, уңнан - 1,5, сулдан - 2,5, астан - 2, өстән - 1,5) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла.

Титул битенә белем бирү оешмасының тулы исеме, районы, укучының фамилиясе, исеме, этисенең исеме, сыйныфы, тема һәм укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

**Эзләнү эшләре түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:**

- укучының теманы ачып бирә алуы, композициянең тулылыгы;
- дәлилле һәм иҗади фикерләү сәләтенә ия булуы;
- эшнең грамоталы, әдәби телдә язылган, китерелгән фактларның дөрес булуы;
- әдәби әсәрләрнең беркая да басылмавы мәҗбүри.

Габдулла Тукай укуларында чыгыш ясау вакыты 3-5 минут.Укучы, бирелгән вакыт эчендә, эчтәлекне ачып, төп фикерләрен әйтеп бирә белергә тиеш (компьютер презентациясе хуплана).

Эшләр (бары тик язмача вариантта) заявка белән бергә 2014 нче елның 18 нче апреленә кадәр Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбенә (422035, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 2 нче йорт) җибәрелә. II турга үткән укучылар хезмәтләренең электрон вариантын үзләре белән алып киләләр.

**Уңышлы дип табылган эш авторларына аерым чакыру җибәреләчәк.**

| № п/п | Ф.И. әтисенең исеме, туган елы | Район, мәктәп, сыйныф | Адрес, индекс | Паспорты буенча мәгълүмат: кем тарафыннан, кайчан бирелгән | Фәнни җитәкченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме. | Элемтә өчен телефон номеры (районның коды) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

**Конкурсны оештыручылар:**

1. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы;
2. Арча районы башкарма комитеты;
3. Арча районы мәгариф идарәсе;
4. Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе;
5. Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте.

**Чыгышларны бәяләү өчен критерийлар:**

- эшнең фәннилеге;
- заман таләпләренә туры килүе;
- әлеге тема өстендә эшләүче галимнәрнең фикеренә таяну;
- эшләрнең җирле материалларга нигезләнгән булуы;
- эшнең максатын дөрес билгеләү;
- логик яктан дөрес фикерләү, дәлилләнгән нәтиҗәләр ясау.

**Габдулла Тукай укуларын йомгаклау һәм нәтиҗә ясау:**

Катнашучыларның чыгышы алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәяләнә. Тикшерү комиссиясе утырышы үткәрелә, җиңүчеләр турында карар чыгарыла. Чыгарылган карар турында беркетмә языла. Җиңүчеләргә дипломнар тапшырыла.

**Белешмәләр өчен телефоннар:**

Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе : 8 (84366) 56-7-36

Арча районы мәгариф идарәсе: 8(84366) 3-30-12; җаваплы белгеч - Галимҗанова Сәфинә Әхмәдулла кызы; электрон адрес: *arskroo.galimzyanova@mail.ru*

Лист согласования к документу № 4775/14 от 31.03.2014
Инициатор согласования: Шарипова А.С. Начальник отдела национального образования
Согласование инициировано: 31.03.2014 11:41

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | - | Согласовано 31.03.2014 11:41 | - |
| 2 | Мустафин Д.М. | - | Согласовано 31.03.2014 11:43 | - |
| 3 | Фаттахов Э.Н. | - | Подписано 31.03.2014 18:49 | - |